Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Аграмак авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 83-1 31.01.2024 ел.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Аграмак авыл җирлеге Советының “Җир салымы турында”
2023 елның 25 октябрендәге 76-2 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 нче бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлеге советы карары:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлеге советы «Җир салымы турында» 2023 елның 25 октябрендәге 76-2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктның 1.2 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:
« Аграмак авыл җирлеге башкарма комитетыннан даими (вакыты чикләнмәгән) файдаланудагы җир кишәрлекләренә карата»;

- 3 пунктта түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац өстәргә:
«җирле үзидарә органнары, гомуми файдаланудагы территорияләр (парклар, скверлар, ял зоналары, урман утырту һ.б.) биләгән җир кишәрлекләренә карата».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Аграмаковка, Татар Тахталы торак пунктларында, шулай ук Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының интернет челтәрендәге //spasskiy.tatarstan.ru/ рәсми сайтында һәм https://pravo.tatarstan.ru/ хокукый мәгълүматның рәсми сайтында урнаштырып, халыкка җиткерелергә тиеш.

Аграмак авыл җирлеге башлыгы Р.Т.Галәветдинова